МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.07.2021 Казан ш. № 11-68

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә)
конкурс үткәрү турында нигезләмәне раслау хакында

“Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль закон, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 1 февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указы, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында” 31 март, 2018 ел, № 397 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм “Татарстан Республикасының дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәне (кушымта итеп бирелә) расларга.
2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының конкурс комиссиясе составында өч елдан күбрәк торучы бәйсез экспертның үз вәкаләтләрен 2021 елның 1 июленә кадәр саклавын;
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының конкурс комиссиясе составында 2021 елның 1 гыйнварына өч елдан кимрәк торучы бәйсез экспертның үз вәкаләтләрен үзен әлеге комиссия составына беренче тапкыр керткәннән соң өч ел узганчы саклавын.
3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:
“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең

эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәне раслау хакында” 09.06.2007 ел, № 11-51;

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 09.06.2007 ел, № 11-51 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 20.06.2011 ел,№ 11-60”;

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 09.06.2007 ел, № 11-51 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 21.09.2011 ел, № 11-83”;

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 22.07.2013 ел, № 17-69; “Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 02.06.2014 ел, № 11-55;

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 27.10.2017 ел, № 11-103;

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 09.06.2007 ел, № 11-51 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү, конкурс комиссиясенең эш тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” 27.06.2018 ел. № 11-68”.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
29.07.2021 ел, № 11-68
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законга, “Татарстан Республикасының дәүләти гражданлык хезмәте турында” 16 гыйнвар, 2003 ел, № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында” 1 февраль, 2005 ел, № 112 Россия Федерациясе Президенты Указына, “Федераль дәүләт органының кадрлар резервына кертү турында нигезләмәне раслау хакында” 1 март, 2017 ел, № 96 Россия Федерациясе Президенты Указына, “ Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмәне раслау хакында” 14 март, 2011 ел, № УП-127 Татарстан Республикасы Президенты Указына, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасын раслау турында” 31 март, 2018 ел, № 397 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына (алга таба – 31 март, 2018 ел, № 397 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) туры китереп, бу Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты аппаратында (алга таба – Казначылык департаменты) Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү буенча конкурс комиссиясенең составы, эш сроклары һәм тәртибе, шулай ук Министрлыкта һәм Казначылык департаментында дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү методикасы билгеләнә.

1.2. Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба – конкурс) түбәндәге максатта үткәрелә:

Россия Федерациясе гражданнарының дәүләти гражданлык хезмәтенә (алга таба – гражданлык хезмәте) керүенә тигез мөмкинлекләр бирүгә конституцион хокукын тәэмин итү;

Министрлыкның һәм Казначылык департаментының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукларын тәэмин итү;

гражданнарның һәм конкурста катнашуга кертелүчеләрнең һөнәри белемен бәяләү, кандидатларның гомуми саныннан гражданлык хезмәтенең вакантлы

вазыйфасын биләү өчен иң кулай кандидатларны сайлау алу, шулай ук аларның тиешле гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив актларында билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү;

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның һәм Казначылык департаментының кадрлар резервын (алга таба – кадрлар резервы) конкурс нигезендә формалаштыру.

1.3. Конкурс дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, аларның гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренш туры килү-килмәвен бәяләүдән гыйбарәт.

1.4. Конкурс игълан итү турында карарны Татарстан Республикасы финанс министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр), Министрлыкның, Казначылык департаментының кадрлар бүлеге башлыгының нигезле докладына туры китереп, кабул итә һәм боерык белән рәсмиләштерә.

1.5. Вакантлы вазыйфаны бирләүгә (кадрлар резервына кертү) конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе нигезендә, бу Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

1.6. Конкурс үткәрелми:

а) билгеле бер вәкаләтләр срогына, гражданлык хезмәтенең “җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр” категорияләре вазыйфаларын биләүгә билгеләнгәндә;

б) вакытлы хезмәт контрактын төзегәндә;

в) гражданлык хезмәткәрен, “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясындагы 1 өлешендә һәм 60.1 статьясындагы 9 өлешендә күздә тотылган очракларда, гражданлык хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә;

г) гражданлык хезмәтенә кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданинны) гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

Конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

а) вазыфаи бурычларны үтәү Министрлыкның һәм Казначылык департаментының норматив акты нигезендә расланыла торган вазыйфалар исемлеге буенча дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган гражданлык хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләгәндә;

б) гражданлык хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә керүче гражданлык хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.7. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

1.8. Конкурста катнашуга кертелмәгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйффасын биләүгә дәгъва кылучыларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланганнан соң өч көн эчендә язмача гариза буенча үзләренә кире кайтарып бирелергә мөмкин. Моңа кадәр документлар Министрлыкта, Казначылык департаментында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашуга электрон рәвештә тапшырылган документ

лар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

1.9. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына барып кайту, торак бүлмәне наймга алып тору, яшәү, элемтә чараларыннан файдалану һ.б.) кандидатлар тарафыннан үзләренең средстволары хисабына хәл ителә.

## II. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эш тәртибе

2.1. Конкурслар үткәрү өчен Министрлыкта, Казначылык департаментында министр боерыгы нигезендә даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе оештырыла. Конкурс комиссиясе эшенең объективлыгын һәм бәйсезлеген арттыру һәм конкурсларны нәтиҗәле оештыру максатыннан, гражданлык хезмәте вазыйфаларының төрле категорияләре һәм төркемнәре өчен министр карары нигезендә аның составын билгеле бер вакыттан соң алыштырып тору хәл ителә. Комиссия составы министр боерыгы белән раслана.

2.2. Конкурс комиссиясе комиссия рәисеннән, рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясе эшчәнлегенә конкурс комиссиясе рәисе җитәкчелек итә. Конкурс комиссиясе рәисе вакытлыча кая да булса киткән очракта, аның эшчәнлегенә җитәкчелек итүне конкурс комиссиясе рәисе урынбасары хәл итә.

Конкурс комиссиясе секретаре комиссия эшен тәэмин итә (гаризалар кабул итә, эшләрне формалаштыра, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерә һ.б.). Конкурс комиссиясе секретаре вакантлы вазыйфаны биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатларны бәяләүдә катнаша, һәм улконкурс комиссиясе тарафыннан карарлар кабул ителгәндә тавыш бирү хокукына ия.

Конкурс комиссиясе секретаре вакытлыча кая да булса киткән очракта, аның бурычлары конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан комиссия әгъзаларының берсенә йөкләнә.

2.4. Конкурс комиссиясенә министр һәм (яки) аның тарафыннан вәкаләт бирелгән гражданлык хезмәткәрләре (шул исәптән кадрлар бүлегеннән һәм гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә үзендә конкурс үткәрелә торган подразделениедән (кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган гражданлык хезмәте вазыйфалары төркеме буенча профессиональ хезмәт эшчәнлеше өлкәсен хәл ителә торган подразделение), Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук бәйсез экспертлар – фәнни, мәгариф оешмалар вәкилләре һәм гражданлык хезмәткәрләре профессиональ хезмәт эшчәнлегенең тиешле өлкәләрендә һәм төрләрендә кадрлар технологияләре һәм гражданлык хезмәте мәсьәләләре буенча белгечләр булып торучы, закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә, министр запросы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакырыла торган башка оешмалар вәкилләре керә.

Конкурс комиссияләре составына кертелә торган Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет карарлары нигезендә билгеләнә.

Министрлыкның конкурс комиссиясендә бәйсез эксперт булып торуның гомуми срогы өч елдан артмаска тиеш. Әлеге срокны исәпли башлау бәйсез

экспертны конкурс комиссиясе составына беренче тапкыр керткәннән соң хәл ителә. Әлеге бәйсез экспертны конкурс комиссиясе составына кабат кертү конкурс комиссиясе составында булу срогы тәмамланганнан соң кимендә өч ел узганнан соң гына хәл ителергә мөмкин.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.

2.5. Вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт сере булып торучы мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законы нигезләмәләреннән чыгып булдырыла.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырдай мәнфәгатьләр бәрелешенә китерү ихтималын юкка чыгарырдай итеп булдырылырга тиеш.

2.7. Конкурс комиссиясе хокуклы:

а) Министрлыкның, Казначылык департаментының структур подразделениеләре җитәкчеләреннән конкурс комиссиясе эше өчен кирәкле мәгълүматларны һәм материалларны соратып алуга;

б) министрга конкурс комиссиясе компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертүгә.

2.8. Конкурс комиссиясе утырышы гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертүгә) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм анда конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән ике өлеше катнашканда, узды, дип санала. Фәкать гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары катнашында гына конкурс комиссиясе утырышын уздырырга ярамый.

2.9. Кандидат белән конкурс комисиясе күзгә-күз индивидуаль әңгәмә үткәрмичә генә конкурс җиңүчесен билгеләү турында конкурс комиссиясе карарын кабул итү рөхсәт ителми.

2.10. Конкурс комиссиясе тарафыннан, аның әгъзасы яки кандидат тәкъдиме буенча, видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булганда) утырыш үткәрү турында карар, мондый карарның сәбәбен (нигезләнешен) күрсәтеп, кабул ителергә мөмкин.

2.11. Конкурс комиссиясе карары кандидат югында кабул ителә, һәм ул аны гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләүгә яки мондый билгеләүдән баш тартуга нигез булып тора.

Конкурс комиссиясе шулай ук, конкурста җиңмәгән, әмма һөнәри һәм шәхсән сыйфатлары югары бәяләнгән кандидатны гражданлык хезмәте вазыйфаларына биләү өчен Министрлыкның, Казначылык департаментының кадрлар резервына кертү турында рекомендация характерында карар кабул итүгә хокуклы. Әлеге кандидат туплаган балларның гомуми суммасы максималь баллның кимендә 50 процентын тәшкил итәргә тиеш.

2.12. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларының гади күпчелек тавышы

белән, ачык тавыш бирү нигезендә кабул ителә. Тавышлар бертигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

2.13. Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе карары белән рәсмиләштерелә, аңа, бу Нигезләмәгә №1 кушымта нигезендәге форма буенча, конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретарь һәм утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары кул куя.

Кадрлар резервына кертүгә конкурс йомгаклары буенча комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе нигезендә рәсмиләштерелә, аңа, бу Нигезләмәгә №2 кушымта нигезендәге форма буенча, конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары, секретарь һәм утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары кул куя.

Әлеге карарда һәм беркетмәдә, конкурс комиссиясенең бәяләү нәтиҗәләре буенча кандидатларның тупланган балларын һәм алган урыннарын күрсәтеп, кандидатларның рейтингы урын ала.

2.14. Конкурс комиссиясе эшен оештыру һәм тәэмин итүне Министрлыкның, Казначылык департаментының кадрлар бүлеге хәл итә.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста катнашуга 18 яшькә җиткән, Россия Федерациясе дәүләт телен белүче һәм Россия Федерациясе гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе законында билгеләнгән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүче Россия Федерациясе гражданнары хокуклы.

3.2. Гражданлык хезмәткәре, конкурс үткәрү чорында нинди вазыйфа биләвенә бәйсез рәвештә, гомуми нигезләрдә конкурста катнашуга хокуклы.

3.3. Конкурста катнашуга Министрлыкта, Казначылык департаментында гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатларга карата таләпләргә туры килүче һәм бу Нигезләмәнең 3.10 пунктында күздә тотылган срокта бу Нигезләмәнең 3.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыручы гражданнар кертелә.

3.4. Гражданин (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын (кадрлар резервы гражданлык хезмәте вазыйфасын) биләү өчен квалификация таләпләренә туры килмәгәндә, шулай ук “Россия Федерациясенең дәүләти гражданлык хезмәте турында” 27 июль, 2004 ел, № 79-ФЗ Федераль законда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә к онкурста катнашуга кертелми.

3.5. Министрлыкта, Казначылык департаментында гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатларга карата таләпләр дәүләти гражданлык хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.6. Конкурста катнашуга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданины Министрлыкка, Казначылык департаментына тапшыра:

Бу Нигезләмәгә № 3 кушымта нигезендәге форма буенча шәхсән гариза;

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган формада тутырылып, имза салынган анкета, фотосурәте белән;

паспорт яки аны алыштыручы документ күчермәсе ( тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә;

кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслаучы документлар;

нотариуста расланган яки хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе һәм (яки) Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яки) гражданинның хезәт (хезмәт итү) эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәт (хезмәт итү) эшчәнлегенә тәүге тапкыр керешү очракларыннан тыш);

белеме һәм квалификациясе турында документлар күчермәләре, шулай ук, гражданинның теләгенә карап, өстәмә һөнәри белем бирү нәтиҗәләре буенча квалификаци күтәрүне яки квалификация бирелүне раслаучы документлар, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турында документлар кчермәләре – нотариуста расланган яки хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәтендә расланган;

гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә яки аны үтүенә комачаулардай чирдән интекмәве турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 14 декабрь, 2009 ел, N 984н боерыгы белән расланган учет  формасы 001-ГС/у);

Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында күздә тотылган башка документлар.

3.7. Министрлыкта, Казначылык департаментында гражданлык хезмәте вазыйфасын биләүче һәм конкурста катнашырга теләк белдерүче гражданлык хезмәткәре министр исеменә гариза гына тапшыра.

Башка дәүләт органында вазыйфа биләп, конкурста катнашырга теләк белдергән гражданлык хезмәткәре Министрлыкка, Казначылык департаментына министр исеменә гариза һәм, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган форма буенча тутырылган, имзаланган һәм дәүләт органының кадрлар хезмәте раслаган анкета, фотосурәте белән, тапшыра.

3.8. Гражданинның (гражданлык хезмәткәренең) ризалыгы белән аның дәүләт сере һәм закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләвенә рөхсәт бирүне рәсмиләштерү  процедурасы үткәрелә, гражданин (гражданлык хезмәткәре) дәгъва кыла торган гражданлык хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый мәгълүматлардан файдалануга бәйле булган очракта.

3.9. Гражданинның министр исеменә тапшырылган мәгълүматларының дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә автоматлаштырылган тикшерү уза.

3.10. Бу Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.7 пунктларында күрсәтелгән документлар, “Россия Федерациясе дәүләти гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы” федераль дәүләт мәгълүмат системасының (алга таба – Федераль мәгълүмат системасы) рәсми сайтында документларны кабул итү турында белдерү урнаштырылганнан соң 21 календарь көне эчендә, гражданин

(гражданлык хезмәткәре) тарафыннан Министрлыкка, Казначылык департаментына, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, шәхсән, почта аша җибәрү юлы белән яки Федераль мәгълүмат системасыннан файдалану нигезендә электрон рәвештә тапшырыла.

Нигезле сәбәпләрсез, документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмендә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданинга (гражданлык хезмәткәренә) ааларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Нигезле сәбәпләр белән документлар вакытында тапшырылмаганда, аларны тулы күләмендә тапшырмаганда яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда, министр аларны кабул итү срокларын күчерүгә хокуклы.

## IV. Конкурслар үткәрүгә әзерләнү

4.1. Конкурс үткәрүгә әзерләнү кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләүне (алга таба – бәяләү ысуллары) һәм аларга тиешле конкурс биремнәрен формалаштыруны, кирәк булганда, конкурс игълан итү планлаштырыла торган гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына карата гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентлары нигезләмәләрен актуальләштерүне күздә тота.

4.2. Гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентлары нигезләмәләрен актуальләштерү, бәяләү ысулларын сайлау һәм аларга тиешле конкурс биремнәрен формалаштыру, Министрлыкның, Казначылык департаментының кадрлар бүлеге белән килештереп, Министрлыкның, Казначылык департаментының кызыксынулы подразделениесе тарафыннан хәл ителә. Конкурс комиссиясе әгъзалары бәяләү ысулларын куллану һәм конкурс биремнәрен формалаштыру турында тәкъдимнәр кертүгә хокуклы.

Министр карары буенча гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентларында конкрет белгечлеккә (әзерләнү юнәлеше) карата квалификация таләпләре билеләнергә мөмкин.

4.3. Конкурс процедуралары барышында кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның квалификация таләпләренә туры килүен бәяләү өчен федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларына каршы килмәгән бәяләү ысуллары кулланылырга мөмкин, индивидуаль әңгәмәләшүне, анкета узу, төркемләп дискуссияләр уздыруны, документ проектын әзерләүне, реферат язуны һәм башка язмача эшләрне, практик биремнәр чишүне яки вакантлы гражданлык хезмәте вазыйфасы (кадрлар резервы өчен дәүләт хезмәте вазыйфаларының төркеме) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләр буенча тест узуны кертеп.

## V. Конкурс үткәрүне оештыру

5.1. Конкурс ике этапта уздырыла.

5.2. Беренче этапта Министрлыкның, Казначылык департаментының кадрлар бүлеге оештыра:

Министрлыкның һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларында конкурс үткәрү турында мәгълүматлар әзерләү һәм урнаштыруны, мәгълүматлар түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

- гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфалары) атамасы;
- әлеге вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре;
- гражданлык хезмәтен узу шартлары;

дәүләти гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тарафыннан Министрлыкка, Казначылык департаментына тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты;

- әлеге документларны кабул итү срогы;
- конкурсны үткәрүнең күздә тотылган көне;
- аны үткәрү урыны һәм тәртибе;
- бәяләү ысуллары турында мәгълүматлар, шулай ук гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи регоаменты нигезләмәләре – вазыйфаи бурычларынмүз эченә алган;
- хокуклар һәм вазыйфаи бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өченҗаваплылык;
- гражданлык хезмәткәренең профессиональ хезмәт эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре;
- Федераль мәгълүмат системасында урнаштырылган башлангыч квалификация тестына сылтама, башка мәгълүмати материаллар;

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерү;

гражданинның (гражданлык хезмәткәре) квалификация таләпләренә (һөнәри белеме дәрәҗәсе, гражданлык хезмәте (гражданлык хезмәтенең башка төрләре) стажы яки белгечлек буенча эш стажы (тәҗрибә), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле профессиональ белемнәре һәм күнекмәләре) туры килүен тикшерү.

5.3. Дәгъвачылар өчен конкурслар барышында кулланыла торган бәяләү ысуллары турында мәгълүматлар алу мөмкинлеген арттыру, шулай ук дәгъвачының һөнәри дәрәҗәсен үстерүгә, үзлегеннән әзерләнүгә кызыксынучанлыгын көчәйтү максатыннан чыгып, ул үзенең һөнәри дәрәҗәсен конкурс кысаларыннан тыш мөстәкыйль бәяли алсын өчен башлангыч квалификация тестын (алга таба – башлангыч тест) узарга мөмкин, конкурс турында белдерүдә бу хакта күрсәтелә.

Башлангыч тест дәгъвачыларның Россия Федерациясе дәүләт телен (рус телен), Россия Федерациясе Конституциясе нигезләрен, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын ни дәрәҗәдә белүләрен, мәгълүмати-коммуникация технологияләре өлкәсендәге белемнәрен һәм күнекмәләрен бәяләү өчен биремнәрне үз эченә ала.

Башлангыч тест Федераль мәгълүмат системасы рәсми сайтына урнаштырыла, дәгъвачылар аны бушлай уза.

Дәгъвачының башлангыч тестны узу нәтиҗәләре конкурс комиссиясе тарафыннан игътибарга алына алмый, һәм алар конкурста катнашуга аннан документларын кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора алмый.

5.4. Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясе башка норматив-хокукый актлары нигезендә гражданинның гражданлык хезмәтенә керүенә комачаулардай хәлләр билгеләнгәндә, министр аңа язмача рәвештә конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында хәбәр итә. Гражданин конкурста катнашуга документларын электрон рәвештә тапшырган очракта, конкурста катнаштырудан баш тарту сәбәпләре турында хәбәрнамә аңа, Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

5.5. Конкурста катнашуга кертелмгән вакантлы вазыйфа биләүгә дәгъвачы бу карарга Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

5.6. Конкурсның беренче этабы төгәлләнү шарты булып Министрлыкта, Казначылык департаментында гражданлык хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килердәй кимендә ике кандидатның булуы тора, бу кандидатларны алга таба сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаган очракта яки вазыйфага карата квалификация таләпләрен канәгатьләндерердәй бер генә кандидат булган очракта, кокурс, узмады, ди п таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка, кандидатлар таләп ителгән санда булмау сәбәпле, конкурсның, узмады, дип танылуы турында язмача хәбәр ителә.

5.7. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач, министр конкурсның икенче этабын үткәрү датасы (әмма катнашу өчен документлар кабул итү төгәлләнгән көннән соң 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт сере яки башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар белән эшләүгә рөхсәт рәсмиләштерү очрагында, конкурсның икенче этабын үткәрү срогын министр билгели.

Министрлыкның, Казначылык департаментының кадрлар бүлеге конкурсның икенче этабы башланырга кимендә 15 календарь көне калганда, Министрлыкның һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсм и сайтларында аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүматлар, конкурста катнашуга кертелгән кандидатларның исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга язмача рәвештә тиешле хәбәрләр җибәрә, шул ук вакытта конкурста катнашуга документларын электрон рәвештә тапшыруган кандидатларга – Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.

5.8. Конкурсның икенче этабында хәл ителә:

кандидатлар турында мәгълүматларны “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составы бердәм мәгълүмат системасы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Бердәм мәгълүмат кадрлар системасы) кертү;

конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхсән сыйфатларын бәяләү;

Министрлыкта, Казначылык департаментында гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертүгә) конкурс җиңүчесен билгеләү турында конкурс комиссиясе тарафыннан карар кабул итү;

конкурс нәтиҗәләрен бердәм мәгълүмат кадрлар системасына кертү;

конкурс нәтиҗәләрен Министрлык һәм Федераль мәгълүмат системасы сайтларында бастыру.

5.9. Конкурс процедуралары барышында кандидатлар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәүгә контрольлекне тәэмин итү максатыннан чыгып, анда конкурс комиссиясе вәкилләре катнаша. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурс комиссиясе утырышы башланырга кимендә өч эш көне кала кандидатлар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәү материаллары белән танышырга тиеш. Күрсәтелгән материаллар исемлеге конкус комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләнә.

5.10. Кандидатлар конкурс биремнәрен үтәгәндә һәм конкурс комиссиясе утырышы уздырылыганда, министр карары буенча тиешле конкурс процедуралары үткәрелүнең видео- һәм аудиосын яздыру яисә стенограммасын яздыру алып барыла.

5.11. Конкурс уздырылганда, конкурс комиссиясе кандидатлар тарафыннан тапшырылган белеме, гражданлык хезмәтен һәм башка дәүләт хезмәте үтүе, бүтән төрле хезмәт эшчәнлеген алып баруы турындагы документлары, шулай ук, бәяләү ысулларын кулланып – ә алар тест, анкета, индивидуаль әңгәмә, реферат яки башка язмача эшләрне, документ проектын әзерләүне күздә тота – конкурс процедуралары нәтиҗәләре нигезендә, кандидатларны бәяли. Конкурс үткәрелә торган вазыйфалар төркеменә һәм категориясенә бәйле рәвештә, төрле ысуллар кулланылырга мөмкин. Шул ук вакытта кандидат белән тест уздыру һәм индивидуаль әңгәмә үткәрү барлык кандидатлар өчен мәҗбүри ысуллар булып тора.

